ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында” Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында”**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында” 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5; 2013, № 10; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә “балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр башкаруга җәлеп итү” сүзләрен “балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга, хокукка каршы һәм (яисә) җәмгыятькә каршы башка гамәлләр башкаруга җәлеп итү очракларын, шулай ук аларны үз-үзләренә кул салуга этәрү” сүзләренә алмаштырырга;

2) 13 статьяда:

а) 8 пунктта “хезмәттә һәм” сүзләрен төшереп калдырырга, “билгеләүдә ярдәм итүне,” сүзләреннән соң “балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру буенча (аларның ризалыгы белән) ярдәм күрсәтүне,” сүзләрен өстәргә;

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда балигъ булмаганнарны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан чыгаруга кагылышлы мәсьәләләрне һәм аларны укытуга бәйле башка мәсьәләләрне карый;”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ 73-ТРЗ